КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июль г.Казань № 546

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүдә озатып йөреп булышлык күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 15 август, 574 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүдә озатып йөреп булышлык күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалидларны инвалидларны эш белән тәэмин итүдә озатып йөреп булышлык күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 15 август, 574 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1139 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүдә озатып йөреп булышлык күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Конкурс юридик затларның һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләрнең инвалидларны (шул исәптән югары, урта һөнәри белем бирүнең, һөнәри укытуның, өстәмә һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алып бетерүчеләрне), реабилитацияләү яки абилитацияләү буенча индивидуаль программада тәкъдим ителә торган хезмәт эшчәнлегенең яраган (ярамаган) төрләрен исәпкә алып, эш белән тәэмин итүдә озатып йөреп булышлык күрсәтү эшчәнлеге буенча проектлар сайлап алу максатларында үткәрелә.

Проектларда түбәндәге чаралар күздә тотылырга тиеш:

Татарстан Республикасының хезмәт базарына анализ ясау һәм инвалидлар өчен (шул исәптән белем алып, укып бетергәннән соң белем бирү оешмаларын һәм укытуны гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаучылар арасыннан) вакансияләрнең шәхсиләштерелгән исемлеген төзү;

инвалидларны озатып йөреп эш белән тәэмин итүне оештыру өчен алар арасыннан укуны тәмамлаучыларның максатчан аудиториясен алдан ук билгеләү өчен белем бирү оешмалары һәм укытуны гамәлгә ашыручы оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

инвалидларга индивидуаль һөнәри консультация бирүне, аларны һөнәри яраштыруны һәм һөнәри сайлап алуны оештыру;

инвалидларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында потенциаль эш бирүчеләр белән алдан сөйләшүләр үткәрү;

инвалидны эшкә урнаштыру максатларында, эш бирүченең инвалид белән үзара хезмәттәшлеген эш бирүчеләр һәм инвалидлар белән килештереп оештыру, инвалидларга әңгәмәгә әзерләнүдә ярдәм күрсәтү, эш бирүче белән әңгәмә үткәрү барышында инвалидны озатып йөрү һәм аңа ярдәм күрсәтү;

инвалидның һөнәри укуы һәм өстәмә һөнәри белем алуы кирәклеген билгеләү һәм инвалидка һөнәри укуда һәм өстәмә һөнәри белем алуда ярдәм күрсәтү;

инвалидның ихтыяҗын исәпкә алып, аның эш урынына кадәр һәм эш бирүче оешма территориясендә хәрәкәт итү маршрутын формалаштыру;

инвалид өчен эш бирүче оешманың кирәкле хезмәт бүлмәләреннән һәм мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү;

эш бирүче оешмада махсус эш урынын җиһазландыру (кирәк-яраклар белән тәэмин итү) буенча чараларны билгеләү;

хезмәт законнары нормаларын исәпкә алып, инвалидның эш көне тәртибе үзенчәлекләрен билгеләү;

эш бирүче оешманың инвалид белән эшләүче белгечләренә аңа хезмәт йөкләмәләрен үзләштерүдә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү;

эш бирүче белән берлектә, эш бирүче тарафыннан остазлык итүне оештыру кирәклеген билгеләү һәм, кирәк булган очракта, эш бирүчегә остазлык итүне оештыруда ярдәм күрсәтү, шул исәптән остазны инвалидның хезмәт йөкләмәләре һәм хезмәт шартлары белән таныштыру;

эшкә урнаштырылган инвалидларның эш урыннарында адаптациясе барышын анализлау, инвалид тарафыннан хезмәт йөкләмәләрен үтәүгә комачаулый торган барьерлар булу-булмавын һәм аның адаптациясе буенча булган проблемаларны ачыклау, эш бирүче белән килештереп, эш урынында инвалидның адаптациясе

буенча ачыкланган проблемаларны бетерүгә һәм аны һөнәри формалаштыруга һәм үстерүгә ярдәм итә торган чаралар системасын булдыру һәм тормышка ашыру;

проектны тормышка ашыру этапларын тикшерү максатларында, квартал саен Татарстан Республикасының кызыксынучы башкарма хакимият органнары, инвалидларның, эш бирүчеләрнең иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнашында очрашулар үткәрү;

массакүләм мәгълүмат чараларында проектны тормышка ашыру барышын яктырту;

инвалидларның иҗтимагый оешмалары, белем бирү оешмалары вәкилләре, эш бирүчеләр, кызыксынучы министрлыклар катнашында проектны тормышка ашыру йомгаклары буенча «түгәрәк өстәл» утырышын үткәрү;

инвалидларны эш белән тәэмин итүдә озатып йөреп булышлык күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру кысаларында юридик зат һәм (яки) индивидуаль эшмәкәр тарафыннан тормышка ашыру өчен мөстәкыйль тәкъдим ителгән, Тәртипнең 1 нче пунктында бәян ителгән максатларга туры килә торган башка чаралар үткәрү.

Проектта озатып йөреп эш белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтеләчәк инвалидларның күздә тотыла торган саны, шул исәптән белем бирү оешмаларын һәм укытуны гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаучыларның гомуми саны турында мәгълүмат булырга тиеш.

Проект үз эченә аны тормышка ашыру нәтиҗәлелегенең түбәндәге күрсәткечләрен алырга тиеш:

югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты һәм аннан да артыграк ай үткәч, эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча алты һәм аннан да артыграк ай үткәч, эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

һөнәри укыганнан соң өч ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

һөнәри укыганнан соң алты ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

һөнәри укыганнан соң алты һәм аннан да артыграк ай үткәч, эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

өстәмә һөнәри программаларны (квалификацияне күтәрү программаларын һәм һөнәри яңадан әзерләү программаларын) үзләштергәннән соң өч ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

өстәмә һөнәри программаларны (квалификацияне күтәрү программаларын һәм һөнәри яңадан әзерләү программаларын) үзләштергәннән соң алты ай эчендә эш тапкан, яшь һәм эше булган инвалидларның өлеше;

югары белем алганнан соң алга таба укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укуны тәмамлаучыларның өлеше;

урта һөнәри белем алганнан соң алга таба укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укуны тәмамлаучыларның өлеше.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләренең мәгънәләре Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү чаралары кысаларында яшь инвалидларны эшкә урнаштырганда озатып йөрү буенча бертип программаны раслау турында» 2017 ел, 23 август, 625 нче боерыгы нигезендә исәпләп чыгарыла.»;

39 нчы пунктта «46» санын «38» санына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин